| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.12.2024 Казан ш № 801

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 213 статьясын, «Хезмәт шартларын махсус бәяләү турында» 2013 елның 28 декабрендәге 426-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законнарны үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелә торган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.Ф.Вәлиуллловка йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2024 елның
2 декабрендәге 801 номерлы
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен (алга таба – дәүләт хезмәте), дәүләт хезмәте күрсәткәндә административ процедураларның (гамәлләрнең) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып хезмәткәрләр, эш бирүчеләр, аларның берләшмәләре, һөнәри берлекләр, аларның берләшмәләре, хезмәткәрләр тарафыннан вәкаләт бирелгән башка вәкиллекле органнар (шундыйлар булган очракта), бәхетсезлек очракларын тикшерү комиссияләре, хезмәт шартларын махсус бәяләгән оешмалар (хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырылган очракта) тора.

Әгәр мөрәҗәгать итүче хезмәткәр булса, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы аның эш урынындагы (эш урыннарындагы) хезмәт шартларына карата гына үткәрелә.

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эш бирүчеләрнең эш урынына (эш урыннарына) карата гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче исеменнән Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкил дә эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) мөрәҗәгать итүченең профилен яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру.

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы түбәндәгеләрне бәяләү максатларында гамәлгә ашырыла:

хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру сыйфаты;

хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләгән өчен гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеге (Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә даими нигездә эш итүче филиаллары, вәкиллекләре һәм (яисә) бүлендек җәмгыятьләре булган компанияләр төркемнәренә (корпорацияләр, холдинглар һәм юридик затларның башка берләшмәләре) кергән оешмалар хезмәткәрләреннән тыш);

хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартлары.

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыру объекты булып эш урыны (эш урыннары) тора (алга таба – экспертиза объекты).

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

2.2.2. Күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе;

хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеген бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе;

хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартларын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе;

хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырудан баш тарту турында хәбәр.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.3. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе реквизитлары:

бәяләмәнең номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), почта адресы – физик затлар өчен, тулы исеме, почта адресы – юридик затлар өчен;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта).

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздырудан баш тарту турында хәбәр реквизитлары:

баш тарту турында хәбәрнең номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) – физик затлар өчен, тулы исеме – юридик затлар өчен;

хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздырудан баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр;

вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта).

2.3.4. Хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына уздырылган дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре турында белешмәләр Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы) урнаштырыла.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) кулга бирелә;

тапшыру турында хәбәр белән почта аша хат итеп җибәрелә,

электрон почтага көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәте гариза һәм документлар Министрлык тарафыннан теркәлгән көннән алып 30 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру өчен кирәкле документация һәм материалларны алу һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру тәртибен раслау турында» 2021 елның 29 октябрендәге 775н номерлы боерыгы белән расланган Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру тәртибендә күрсәтелгән тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү кирәк булган очракта яисә аларны срок дәвамында үткәрү мөмкин булмаса, әлеге Регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы озайтылырга мөмкин, ләкин ул 60 эш көненнән дә артмаска тиеш.

2.4.3. Эш бирүчегә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объекты булып торган эш урыны буенча документлар соратып алу җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү соратып алына торган документларны алганчыга кадәрге вакытка, әмма 30 эш көненнән дә артмаган вакытка туктатыла.

2.4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр билгеләнгәндә, Министрлык гариза теркәлгән көннән алып 12 эш көненнән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелгән хәбәрне җибәрү юлы белән, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын үткәрүнең мөмкин түгеллеге турында хәбәр итә.

2.4.5. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (кулга, хәбәрне почта аша яисә электрон почтага җибәрү юлы белән) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе расланган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mtsz.tatar.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (документларның күчермәләре) исемлеге:

2.6.1.1. Әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән гариза.P534

Гаризада күрсәтелә:

а) мөрәҗәгать итүченең тулы исеме (юридик затлар өчен), мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (физик затлар өчен);

б) мөрәҗәгать итүченең почта адресы, электрон почта адресы (булган очракта);

в) хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы максатының исеме;

г) эш урынының индивидуаль номеры (Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру методикасын, Зарарлы һәм (яисә) куркыныч җитештерү факторлары классификаторын, хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру турында хисап рәвешен һәм аны тутыру буенча аңлатмалыкны раслау хакында» 2023 елның 21 ноябрендәге 817н номерлы боерыгының 4 нче кушымтасының 4 пункты нигезендә), эш бирүченең структур бүлекчәсен (булган очракта) һәм хезмәт шартларына карата хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрелергә тиешле эш бирүченең тулы исемен күрсәтеп, әлеге эш урынында эшләүче хезмәткәрнең (хезмәткәрләрнең) һөнәре (вазыйфасы) исеме;

д) хезмәт шартларына элек уздырылган дәүләт экспертизалары турында белешмәләр (булган очракта);

е) хезмәт шартларына махсус бәя бирүне уздыру сыйфатын бәяләү максатларында үткәрелгән очракта, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы өчен түләү турында белешмәләр.

Әгәр мөрәҗәгать итүче физик зат булса, гариза биргәндә өстәмә рәвештә әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы нигезендә шәхси белешмәләрне эшкәртүгә язма ризалык бирелә, ул гаризага теркәлә.

Әгәр мөрәҗәгать итүче эш бирүче булса, ә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасының максаты хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү булса, гаризага өстәмә рәвештә әлеге эш бирүченең хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешма (оешмалар) турында белешмәләр, аның билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларның ул таныклаган күчермәләре теркәлә: хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар реестрында теркәлү турында хәбәр, аккредитация аттестаты һәм хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешманың сынау лабораториясенең (үзәгенең) аккредитацияләү өлкәсен теркәү турында хәбәр, ул аккредитация аттестатының аерылгысыз өлеше булып тора, хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешманың экспертлары сертификатлары.

Әгәр документларны эш бирүче тапшыра алмаса, гаризада аларны тапшырмау сәбәпләре турында мәгълүмат чагылдырыла.

Әгәр мөрәҗәгать итүче хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыручы оешма булса, ә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасының максаты булып хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү торса, гаризага аның

билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларның күчермәләре теркәлә: хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар реестрында теркәлү турында хәбәр, аккредитация аттестаты һәм сынау аккредитация аттестатының аерылгысыз өлеше булган лабораторияләр (үзәк), экспертлар сертификатлары.

2.6.1.2. Эш бирүче мөрәҗәгать итүче булган очракта, гаризага ул таныклаган түбәндәге документларның күчермәләре өстәмә рәвештә теркәлә:

а) хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру өчен:
2020 елның 1 гыйнварыннан соң расланган хисаплар өчен мәгълүмат белән эш бирүче тарафыннан расланган хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап (алга таба – хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап), хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапны Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру турында (2020 елның 1 гыйнварына кадәр расланган хисапларга карата Министрлык мондый хисапларның Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында булуын мөстәкыйль рәвештә билгели), шулай ук хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап материалларына кушымта, аларның исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән;

хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар, шул исәптән «Хезмәт шартларын махсус бәяләү турында» 2013 елның 28 декабрендәге 426-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 426 номерлы федераль закон) таләпләре үтәлешенә дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын үткәрү барышында ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында дәүләт хезмәт инспекцияләре вазыйфаи затлары күрсәтмәләре) (булган очракта);

б) хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеген бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен:

2020 елның 1 гыйнварыннан соң расланган хисаплар өчен хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап, хисапны Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру турында (2020 елның 1 гыйнварына кадәр расланган хисапларга карата Министрлык мондый хисапларның Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында булуын мөстәкыйль рәвештә билгели), шулай ук хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап материалларына кушымта, аларның исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән;

җитештерү мохитенең һәм эш урыннарындагы хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларын тикшерү (сынау) һәм үлчәү нәтиҗәләрен үз эченә алган документлар (булган очракта);

коллектив шартнамә (булган очракта), хезмәт шартнамәсе (хезмәт шартнамәләре), эш бирүченең хезмәткәрләрнең имин хезмәт шартларына, шулай ук зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләүгә бәйле гарантияләр һәм компенсацияләр бирүгә хокукларын үтәү буенча йөкләмәләрен билгели торган локаль норматив актлар;

хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү системасы турында нигезләмә (булган очракта);

эш бирүченең зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләгән өчен хезмәткәрләргә бирелә торган гарантияләрнең һәм компенсацияләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шул исәптән еллык өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгын, эш вакытының кыскартылган дәвамлылыгын, хезмәт өчен түләүне арттыру күләмен билгели торган локаль норматив актлары;

билгеле бер вакыт ешлыгы белән медицина тикшерүен узарга тиешле хезмәткәрләр исемлеге;

хезмәткәрләргә соңгы елда уздырылган медицина тикшерүләре нәтиҗәләре турында бәяләмәләрнең күчермәләре;

в) хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартларын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру өчен:

2020 елның 1 гыйнварыннан соң расланган хисаплар өчен хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап, хисапны Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру турында (2020 елның 1 гыйнварына кадәр расланган хисапларга карата Министрлык мондый хисапларның Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында булуын мөстәкыйль рәвештә билгели), шулай ук хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап материалларына кушымта, аларның исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән;

җитештерү мохитенең һәм эш урыннарындагы хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларын тикшерү (сынау) һәм үлчәү нәтиҗәләрен үз эченә алган документлар (булган очракта);

коллектив шартнамә (булган очракта), хезмәт шартнамәсе (хезмәт шартнамәләре), хезмәткәрнең (хезмәткәрләрнең) хезмәт шартларын, хезмәт һәм ял режимнарын да кертеп, билгели торган локаль норматив актлар;

Дәүләт хезмәт инспекцияләре һәм Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәте һәм аның территориаль органнары вазыйфаи затларының билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге чараларын үткәрү барышында ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында (булган очракта) күрсәтмәләре:

алар нигезендә биналарның, корылмаларның һәм җайланмаларның техник торышы, технологик процессларны оештыру, эш урыннарында инструментларның, чималның һәм материалларның торышы, эш урыннарында индивидуаль һәм күмәк саклану чараларын куллану, эш урыннарында хезмәткәрләргә санитария-көнкүреш һәм дәвалау-профилактика хезмәте күрсәтүнең торышы мәсьәләләре, шулай ук хезмәткәрләрнең эш урыннарында хезмәт һәм ял итү режимнары җайга салына торган эш бирүченең норматив хокукый актлары һәм локаль актлары.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучы зат мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Әлеге пунктта санап үтелгән документларга өстәмә рәвештә гаризага өстәмә документлар да теркәлергә мөмкин. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасына

тапшырыла торган, кирәк булганда Министрлык тарафыннан өстәмә рәвештә соратыла торган өстәмә документларның якынча исемлеге шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән. Эш бирүче яисә башка мөрәҗәгать итүчеләр күрсәтелгән документларны гаризага һәм шушы пунктта санап үтелгән документларга өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы. Әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар алынмаган очракта, Министрлык, әгәр аларның булмавы хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыруны тәэмин итәргә мөмкинлек бирмәсә, аларны эш бирүчедән соратып алырга хокуклы.

2.6.2. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Әгәр гариза бирүче хезмәт шартларына махсус бәя бирүче оешма булса, гаризага кушымта итеп бирелә торган документларның күчермәләре күрсәтелгән оешманың җитәкчесе тарафыннан таныклана.

2.6.3. Гариза һәм аңа беркетелә торган документлар шулай ук «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша җибәрелә (тапшырыла) алалар.

2.6.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре юк.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Эш бирүчегә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объекты булып торган эш урыны буенча документлар соратып алу җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү соратып алына торган документларны алганчыга кадәрге вакытка, әмма 30 эш көненнән дә артмаган вакытка туктатыла, мөрәҗәгать итүчегә бу хакта хәбәр ителә.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

а) гаризада шушы Регламентның 2.6.1.1 пунктының «а» - «е» пунктчаларында каралган белешмәләрнең булмавы;

б) мөрәҗәгать итүче эш бирүче булса, гаризага кушып бирелә торган һәм шушы Регламентның 2.6.1.1 һәм 2.6.1.2 пунктларында каралган документлар комплектының мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы, шул исәптән, эш бирүчедә документлар булган очракта, документларны бирү турында Министрлык тарафыннан өстәмә гарызнамәләр җибәрү нәтиҗәләре буенча да;

в) мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6.1.1 пунктында каралган хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыручы оешма булса, аның билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар күчермәләрен тапшырмавы;

г) ялган документлар яисә белә торып ялган белешмәләр тапшыру;

д) Министрлык тарафыннан сорала торган документларны тапшыруның мөмкин түгеллеге турында эш бирүчедән хәбәр;

е) эш бирүченең Министрлыктан соратыла торган документларны Министрлыктан соратып алу датасыннан алып 30 эш көне эчендә тапшырмавы;

ж) хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапның булмавы (тапшырылмавы) һәм хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап турында Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат булмавы;

з) тапшырыла торган документларда хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру максатының шушы Регламентның 2.1 пунктына туры килмәве;

и) шушы Регламентның 1.2 пунктында каралмаган мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итүе;

к) юридик зат ябылганга яисә шәхси эшкуар үз эшчәнлеген туктатканга күрә хисап турында Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында белешмәләр булмавы;

л) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә даими нигездә эш итүче компанияләр төркемнәренә (корпорацияләр, холдинглар һәм юридик затларның башка берләшмәләре) керә торган, филиаллары, вәкиллекләре һәм (яисә) бүлендек җәмгыятьләре булган оешмаларның хезмәткәрләренә карата зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеген бәяләү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүе;

м) үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә булмаган оешмаларның һәм учреждениеләрнең эш урынында (эш урыннарында) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итү.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

2.9.1. Хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы 426-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясындагы 3 өлеше нигезендә мөрәҗәгать итүче акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргән өчен түләү күләме, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән түләүне күчерү өчен банк реквизитлары ел саен Министрлык боерыгы белән билгеләнә, ул Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталында http://pravo.gov.ru бастырып чыгарыла.

Түләүле дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, акчалар мөрәҗәгать итүче керткән күләмдә кире кайтарыла.

2.9.2. Хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеген бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла.

2.9.3. Хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартларын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы түләүсез башкарыла. Җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларын тикшерүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән тикшеренүләрне (сынауларны) һәм үлчәүләрне үткәрү мөрәҗәгать итүче акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең иң күп вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамә ул кергән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлә.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Көтү залларында (урыннарда) мәгълүмат стендлары урнаштырыла, аларда дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәләрнең формалары, аларны тутыру үрнәкләре урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чykканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны

кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Министрлык белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

Мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә мөрәҗәгать итүче барлык документларны тапшырган очракта, үзара хезмәттәшлек итү зарурлыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

әгәр гариза белән документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелсә, – турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми.

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бер хезмәттәшлек итү вакыты 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкта алынырга мөмкин.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

КФҮләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт

хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Министрлыкка, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон чыганаклардан файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.

Гаризаны һәм документларның күчермәләрен электрон документлар рәвешендә биргәндә, мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаны карау барышы турында белешмәләр алырга;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.4. Министрлыкка кабул итүгә мөрәҗәгать итүчеләрне язу (алга таба – язу) Министрлыкның телефон номеры буенча телефон элемтәсе аша башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Министрлыкта билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Телефон элемтәсе аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Мөрәҗәгать итүчедән кабул итү максатын күрсәтүдән тыш башка гамәлләр башкаруны, шулай ук кабул итү өчен броньланырга тиешле вакыт аралыгының озынлыгын исәпләү өчен кирәкле мәгълүмат бирүне таләп итү тыела.

Алдан язылу булмау мөрәҗәгать итүчене чират тәртибендә кабул итүгә комачауламый.

2.14.5. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә дә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

гаризаны теркәлгән документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү;

гаризаны һәм тапшырылган документларны хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объектлары турында алардагы белешмәләрнең тулылыгын һәм аларның хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыру өчен җитәрлек булуын билгеләү максатларында карау;

мөрәҗәгать итүче күрсәткән хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объектына карата хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру;

билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән сынау лабораторияләрен (үзәкләрен) җәлеп итеп, җитештерү мохите һәм хезмәт процессы факторларын тикшерүне (сынауларны) һәм үлчәүләрне үткәрүне (кирәк булганда) оештыру;

хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документтагы техник хатаны (язу, басма хатаны язу, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, почта буенча язмача һәм (яки) электрон почта аша Министрлыкка дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Министрлык белгече шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән ысулның нинди булуына карап, гариза бирүчене, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен зарури булган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияли һәм гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче, шушы Регламентның 2.6 пункты нигезендә

документлар (документларның күчермәләрен) теркәп, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру турында гариза бирә.

Гариза һәм аңа кушымта итеп бирелә торган, Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган документларның күчермәләре почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон рәвештә җибәрелә торган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә имзалана (таныклана) һәм Министрлыкка электрон саклагычлардан һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып тапшырыла алалар.

3.3.2. Министрлык белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле буларак катнашучы затның яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

гаризаны кабул итә һәм электрон документ әйләнеше системасында терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм документлар Министрлыкка алынган көнне яисә, гариза һәм документлар Министрлыкның эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, – аннан соңгы көндә. Гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Министрлыкның ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән документлар, электрон документ әйләнеше системасында теркәү язуы.

3.4. Гаризаны һәм тапшырылган документларны хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объектлары турында алардагы белешмәләрнең тулылыгын һәм аларның хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыру өчен җитәрлек булуын билгеләү максатларында карау.

3.4.1. Дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) гаризаны һәм аңа беркетелә торган документларны теркәгән көннән алып җиде эш көне эчендә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объектлары турында алардагы белешмәләрнең тулылыгын билгели, аларның хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыру өчен җитәрлек булуын билгели һәм хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыру яисә уздырмау мөмкинлеге турында дәүләт экспертизасы җитәкчесенә хәбәр итә.

3.4.2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган һәм (яисә) алардагы белешмәләр хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыру өчен җитәрлек булмаган очракта, дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) эш урыннары хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объекты булган эш бирүчегә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыру өчен кирәкле документларны әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында күрсәтелгән форма буенча тапшыру турында гарызнамә әзерли.

3.4.3. Дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) тарафыннан баш тарту өчен шушы Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр билгеләнгән очракта, дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту

турында әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча хәбәр әзерли.

Экспертиза җитәкчесе, мондый карарны кабул иткәндә, биш эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрелмәве турында хәбәр итә. Баш тарту турында хәбәр тапшыру турында белдерү белән почта аша җибәрелә яисә, «Интернет» челтәреннән файдаланып, электрон документ рәвешендә яисә күрсәтелгән хәбәрне турыдан-туры мөрәҗәгать итүчегә тапшырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: каралган документлар; хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын үткәрү яисә үткәрмәү турында дәүләт экспертизасы җитәкчесенә кертелгән тәкъдим; документларның тулы исемлеген тапшыру турында эш бирүчегә җибәрелгән гарызнамә; мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турында җибәрелгән хәбәр.

3.5. Мөрәҗәгать итүче күрсәткән хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объектына карата хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру

3.5.1. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздырганда хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү максатларында дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапны анализлый, 426-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә туры килү-килмәвенә карата эзлекле рәвештә түбәндәге хәлләрне тикшерә:

а) эш бирүче турындагы белешмәләрнең хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапның титул битендә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы нигезләрендә күрсәтелгән белешмәләргә туры килүен, 2020 елның 1 гыйнварына кадәр расланган хисапның титул битендәге идентификация номеры турындагы белешмәләрнең Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында күрсәтелгән белешмәләргә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасында эш бирүче турындагы белешмәләргә туры килү-килмәвен (2020 елның 1 гыйнварында хисапның титул битендә идентификация номерының булуы һәм туры килүе тикшерелми, хисапның титул битендәге башка мәгълүматларның күрсәтелгән пунктчаның нигезләмәләренә туры килүе билгеләнә).

б) хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапның I бүлегендә:

хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешма, хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруда катнашкан аның экспертлары турындагы мәгълүматларның операторы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы булган тиешле реестрлардагы белешмәләргә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы белешмәләренә туры килү-килмәвен;

хезмәт шартларына махсус бәя биргән оешманың аккредитациясе турындагы белешмәләрнең сертификацияләү органнары һәм аккредитацияләнгән сынау лабораторияләре (үзәкләре) реестрындагы белешмәләргә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы белешмәләренә туры килү-килмәвен;

хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү барышында файдаланылган Үлчәү чараларын үлчәүләр бердәмлеген тәэмин итү буенча федераль мәгълүмат фондында теркәүнең булуын, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы мәгълүматларгаа туры килүен;

хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру барышында кулланылган үлчәү чараларының җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру барышында идентификацияләнгән зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларына, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы белешмәләргә туры килүен;

хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү барышында файдаланылган үлчәү чараларын тикшерү турында белешмәләр булуын, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерергә кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы мәгълүматларга туры килүен;

эш бирүченең хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру комиссиясе составы турындагы белешмәләрнең 426-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясындагы 1-4 өлешләре таләпләренә туры килүе.

в) хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапның II бүлегендә:

эш урыннарын тиңдәшләренә кертүнең дөреслеген (андыйлар булганда), шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы мәгълүматларга туры килүен;

эш урыны (эш урыннары) турындагы белешмәләрнең гаризада күрсәтелгән белешмәләргә туры килүе;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 21 ноябрендәге 817н номерлы боерыгы белән расланган Зарарлы һәм (яисә) куркыныч җитештерү факторлары классификаторы нигезендә җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының тикшерелергә (сыналырга) һәм үлчелергә тиешле зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларын, шулай ук тикшерелә торган эш урынында (эш урыннарында) аларның чыганакларын идентификацияләүнең дөреслеген, шулай ук, кирәк булганда, мәгълүматларның Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен төгәлләштерелә, идентификация үткәрелмәгәндә, Хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапка теркәлә торган тикшеренүләргә (сынауларга) һәм үлчәүләргә тиешле зарарлы һәм (яисә) куркыныч җитештерү факторлары исемлеге нигезендә 426-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясындагы 6 өлеше нигезендә җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының тикшерелергә (сыналырга) һәм үлчәлергә тиешле зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларын билгеләүнең дөреслеге билгеләнә, шулай ук, кирәк булганда, мәгълүматларның Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен төгәлләштерелә;

эш урынын (эш урыннарын) хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап материаллары буенча хезмәт шартларының хезмәтне саклауның дәүләт норматив таләпләренә туры килүе турында декларацияләнергә тиешле дип

санауның, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен төгәлләштерелә.

г) сынаулар (үлчәүләр) беркетмәләрендә:

хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыручы оешма, җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларын тикшерүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәргән экспертлар һәм башка белгечләр турындагы, Сынау лабораториясе (үзәк) турындагы, кулланылган үлчәү чаралары турындагы мәгълүматларның хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапның I бүлегендә күрсәтелгән белешмәләргә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

эш бирүче турындагы мәгълүматларның хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапның титул битендә күрсәтелгән белешмәләргә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

эш урыннары турындагы белешмәләрнең хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапның II бүлегендә күрсәтелгән белешмәләргә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

үлчәнгән (сыналган) зурлыкларның эш урынында (эш урыннарында) идентификацияләнгән һәм хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапның II бүлегендә күрсәтелгән җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларына, шулай ук оешманы аккредитацияләү турындагы белешмәләргә һәм, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү барышында кулланылган тикшеренүләр (сынаулар) методының һәм (яисә) үлчәү методикасының (методының) эш урынында (эш урыннарында) җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларына туры килүен, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү барышында җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларының рөхсәт ителә торган иң чик дәрәҗәләрен яисә рөхсәт ителә торган иң чик концентрацияләрен регламентлаштыра торган норматив хокукый актларны куллануның дөреслеген, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

д) хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапның III бүлегендә:

эш бирүче турындагы мәгълүматларның хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы нигезләрендә һәм хисапның титул битендә күрсәтелгән

белешмәләргә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

хезмәткәр (хезмәткәрләр) һөнәре (вазыйфасы) атамасының Гомумроссия эшче һөнәрләре классификаторында, хезмәткәр вазыйфаларында һәм тариф разрядларында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) атамаларына, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисап составына керә торган Махсус хезмәт шартларын бәяләүнең 030 юлында күрсәтелгән картаның (алга таба – карта) һәм җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларының эш урынында (эш урыннарында) кулланыла торган (эксплуатацияләнә торган) җиһазлар, чимал һәм материаллар исемлегенә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

хезмәт шартлары классын (ярдәмче классын) билгеләүнең дөреслеген, шул исәптән индивидуаль саклану чараларының нәтиҗәлелеген бәяләүне исәпкә алып, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

картаның 040 юлында күрсәтелгән хезмәткәргә (хезмәткәрләргә) гарантияләрне һәм компенсацияләрне билгеләүнең дөреслеген, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен.

е) эш урынында (эш урыннарында) индивидуаль саклану чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү беркетмәсендә күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, аларның картаның 030 юлы күрсәткечләренә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен (булган очракта);

ж) хезмәт шартларын махсус бәяләүне үткәрү нәтиҗәләренең җыелма ведомостенең, карта (карталар) һәм аларга кушып бирелә торган сынаулар (үлчәүләр) нәтиҗәләре беркетмәләре белешмәләре дөреслеген,шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен;

з) эш урынында (эш урыннарында) хезмәт шартларын яхшырту буенча тәкъдим ителә торган чаралар исемлегенең күрсәтелгән эш урынының (эш урыннарының) картаның 050 юлы күрсәткечләренә, шулай ук, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен.

3.5.2. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырганда хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен гарантияләр һәм

компенсацияләр бирүнең дөреслеген бәяләү максатларында, дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапны һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган башка документларны анализлыйлар, аларның хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары, эш бирүченең локаль норматив актлары булган башка норматив хокукый актлар таләпләренә, тармак (тармакара) килешүләренә һәм күмәк шартнамәләргә (булган очракта) туры килүен тикшерәләр, шулай ук зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эш урыннарында эшләүче хезмәткәргә (хезмәткәрләргә) түбәндәге гарантияләр һәм компенсацияләр бирү күләмен һәм тәртибен тикшерәләр:

а) эш атнасының кыскартылган дәвамлылыгы;

б) еллык өстәмә түләүле отпуск;

в) югары күләмдә хезмәт өчен түләү;

г) хезмәт законнарында, хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган норматив хокукый актларда, тармак (тармакара) килешүләрдә, күмәк шартнамәләрдә, эш бирүченең локаль норматив актларында каралган башка гарантияләр һәм компенсацияләр.

3.5.3. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздырганда хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартларын бәяләү максатларында дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) хезмәт шартларына махсус бәяләү үткәрү турында хисапны һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган башка документларны анализлыйлар, хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен эзлекле рәвештә тикшерәләр:

а) хезмәткәрнең (хезмәткәрләрнең) эш урынында (эш урыннарында) җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларының булуын, бирелә торган гарантияләрнең (компенсацияләрнең) булуын билгеләү буенча башкарылган эшләр, мәгълүматны төгәлләштерү кирәк булганда, Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә туры килүен чагыштыру;

б) инструментлар, чимал һәм материаллар, шулай ук эш урынында (эш урыннарында) хезмәткәрне (хезмәткәрләрне) индивидуаль һәм күмәк саклану чараларын җитештерүдә кулланыла торган биналарның, корылмаларның, җайланмаларның, технологик процессларның техник торышы;

в) хезмәткәргә (хезмәткәрләргә) санитария-көнкүреш һәм дәвалау-профилактика хезмәте күрсәтүнең торышы;

г) хезмәткәрнең (хезмәткәрләрнең) билгеләнгән хезмәт һәм ял режимнары;

д) хезмәткәрнең һөнәре (вазыйфасы) атамасының һәм хезмәт функцияләренең квалификация белешмәлекләрендәге һәм һөнәри стандартлардагы квалификация таләпләренә туры килүе;

е) гаризада күрсәтелгән хезмәткәрнең хезмәт шартларын тасвирлаучы өстәмә белешмәләр.

3.5.4. Дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) эш бирүче белән килешү буенча хезмәт шартларына уздырыла торган дәүләт экспертизасы максатларында кирәкле мәгълүмат алу өчен тикшерелә торган эш урынына (эш урыннарына) бара, ә эш бирүче бу очракта дәүләт экспертының (экспертлар комиссиясенең) тикшерелә торган эш урынына (эш урыннарына) керүен тәэмин итә.

3.5.5. Процедураны башкаруның гомуми вакыты гариза теркәлгән көннән алып 25 эш көненнән дә артмый.

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру һәм (яисә) тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү өчен кирәкле документация һәм материаллар алырга кирәк булганда яисә аларны әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок эчендә үткәрү мөмкин булмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы озайтылырга мөмкин, ләкин ул 60 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе: хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объектына карата эксперт бәяләве

3.6. Билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән сынау лабораторияләрен (үзәкләрен) җәлеп итеп, җитештерү мохите һәм хезмәт процессы факторларын тикшерүне (сынауларны) һәм үлчәүләрне үткәрүне (кирәк булганда) оештыру

Гаризада җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларын үткәрелгән тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр нәтиҗәләре белән килешмәү күрсәтелгән очракта, шулай ук хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартларын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәргәндә, билгеләнгән тәртиптә аккредитация узган сынау лабораторияләрен (үзәкләрен) җәлеп итеп, хезмәт шартларына карата хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырыла торган эш урыннарында җитештерү мохитенең һәм хезмәт процессының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларын тикшерүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрелергә мөмкин.

3.6.1. Тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү турындагы карар дәүләт экспертизасы (экспертлар комиссиясе) тәкъдиме буенча дәүләт экспертизасы җитәкчесе тарафыннан кабул ителә һәм үткәрүгә кирәкле тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр күләмен, аларны үткәрүнең шундый ук тикшеренүләр (сынаулар) үткәрү буенча тәкъдимнәрне яисә билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән кимендә өч сынау лабораториясен (үзәкләрен) үлчәүләрне өйрәнү нигезендә билгеләнә торган бәясен исәпләүне үз эченә алырга тиеш.

3.6.2. Тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, дәүләт экспертизасы җитәкчесе ул кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә, шулай ук эш урыннарында тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәреләчәк эш бирүчегә мондый карарны тапшыру турында хәбәр белән почта аша заказлы хат аша яисә, гариза электрон рәвештә җибәрелгән очракта, «Интернет» челтәреннән файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документ рәвешендә карар кабул ителүе турында хәбәр итә.

3.6.3. Мөрәҗәгать итүче акчалары исәбеннән тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрергә кирәк булганда, ул шушы Регламентның 3.6.2 пунктында күрсәтелгән хәбәрне алган көннән алып 10 эш көне эчендә Министрлыкка тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү өчен түләү сыйфатында Министрлыкның тиешле шәхси счетына акча кертүне раслаучы документаль раслауны тапшырырга тиеш.

Тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү өчен түләү билгеләнгән вакытта документаль расланмаган очракта, дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыруның мөмкин булмавы

турында карар кабул итә, бу хакта хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә тиешле язу теркәлә.

3.6.4. Процедураны башкаруның гомуми вакыты гариза теркәлгән көннән алып 24 эш көненнән дә артмый.

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру һәм (яисә) тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү өчен кирәкле документация һәм материаллар алырга кирәк булганда яисә аларны әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок эчендә үткәрү мөмкин булмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы озайтылырга мөмкин, ләкин ул 60 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрмәү турында карар; тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү нәтиҗәләре буенча сынау лабораториясе (үзәк) тарафыннан тапшырылган документларны Министрлык тарафыннан алу.

3.7. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

3.7.1. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре буенча дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе) тарафыннан хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе проекты төзелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы органының исеме, җитәкченең почта адресын, фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), шулай ук хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын үткәргән (уздырган) дәүләт экспертының (экспертлар комиссиясе әгъзаларының) вазыйфасын, фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта) күрсәтеп, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздырган органның исеме;

б) хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы органында теркәү датасын күрсәтеп, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы өчен нигез;

в) мөрәҗәгать итүче турындагы белешмәләр – тулы исеме (юридик затлар өчен), фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (физик затлар өчен), почта адресы;

г) хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын үткәрү чоры, аны үткәрә башлау һәм тәмамлау датасын күрсәтеп;

д) хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыруның максаты;

е) эш урыннарында хезмәт шартларына карата хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырыла торган эш бирүченең яисә аның аерым бүлекчәсенең исеме;

ж) хезмәт шартларына карата хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрелә торган эш урыннары турында белешмәләр (эш урынының индивидуаль номеры, әлеге эш урынында эшләүче хезмәткәрнең (хезмәткәрләрнең) һөнәре (вазыйфасы) исеме);

з) хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы өчен нигезләр составында тапшырылган һәм (яисә) шушы Регламентның 3.4.2 пункты нигезендә алынган документлар исемлеге.

3.7.2. Хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыру нәтиҗәләре буенча төзелгән хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе проектында өстәмә рәвештә хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешма (оешмалар) турында белешмәләр күрсәтелә, алар түбәндәгеләрне үз эченә ала:

а) хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешманың тулы исеме, аның тәртип номеры һәм хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыручы оешмалар реестрына кертү датасы, аккредитацияләү буенча федераль хезмәтнең (Росаккредитация) сынау лабораториясенә (үзәгенә) аккредитацияләү аттестатының номеры һәм аны бирү датасы;

б) хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешманың эксперт фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), хезмәт шартларын махсус бәяләү буенча эшләр башкару хокукына эксперт сертификатының номеры һәм аны бирү датасы.

3.7.3. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы максатыннан чыгып, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе проектында түбәндәге нәтиҗәләрнең берсе була:

а) хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру сыйфатының хезмәт шартларын махсус бәяләү турындагы законнар таләпләренә туры килүе (туры килмәве) хакында;

б) зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә бирелә торган гарантияләрне һәм компенсацияләрне бирүнең (бирмәүнең) һәм күләмнәренең нигезлелеге турында;

в) хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартларының хезмәтне саклауның дәүләт норматив таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында.

3.7.4. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе проекты ике нөсхәдә төзелә, дәүләт эксперты (экспертлар комиссиясе әгъзалары) тарафыннан имзалана һәм дәүләт экспертизасы җитәкчесе тарафыннан раслана.

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсен көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә рәсмиләштерү рөхсәт ителә.

3.7.5. Процедураны башкаруның гомуми вакыты гариза теркәлгән көннән алып 27 эш көненнән артмаска тиеш.

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру һәм (яисә) тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр үткәрү өчен кирәкле документация һәм материаллар алырга кирәк булганда яисә аларны әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срок эчендә үткәрү мөмкин булмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы озайтылырга мөмкин, ләкин ул 60 эш көненнән дә артмаска тиеш.

Дәүләт экспертизасы җитәкчесе тарафыннан расланган хезмәт шартларына экспертизаның рәсмиләштерелгән бәяләмәсе административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.

3.8. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.8.1. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсен раслау датасыннан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, бәяләмәнең бер нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) тапшырыла яисә аңа тапшыру турында хәбәр итү юлы белән почта аша җибәрелә, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә электрон почтага җибәрелергә мөмкин.

3.8.2. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең күчермәләре эш бирүчегә (эш бирүче мөрәҗәгать итүче булмаган очракта) һәм хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешмага (хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздырган оешма мөрәҗәгать итүче булмаган яисә хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы

хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү максатларында уздырылган очракта) җибәрелә.

3.8.3. Хезмәт шартларына уздырылган дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре турында белешмәләр хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү максатларында дәүләт эксперты тарафыннан Хезмәт шартларын махсус бәяләү уздыру нәтиҗәләрен исәпкә алуның федераль дәүләт мәгълүмат системасына җибәрелә.

3.8.4. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе югалган очракта, мөрәҗәгать итүче, әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дубликатын бирүгә гариза биргән очракта, Министрлыкта әлеге бәяләмәнең дубликатын алырга хокуклы.

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең дубликаты, Министрлык тарафыннан аны бирү турында язма мөрәҗәгать алынган көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) тапшырыла яисә аңа тапшырылуы турында хәбәр итү юлы белән почта аша җибәрелә, яисә аңа көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә электрон почтага җибәрелергә мөмкин.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) дәүләт экспертизасы бәяләмәсен яисә дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дубликатын җибәрү (бирү) тора.

3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документтагы техник хатаны (язу, басма хатаны язу, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

Техник хатаны төзәтү мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 8 нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча гариза биргәндә, мөрәҗәгать итүчегә хаталы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документны теркәп гамәлгә ашырыла.

3.9.1. Министрлык белгече:

мөрәҗәгать итүче биргән гаризаны карый һәм гаризада күрсәтелгән белешмәләрне тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм (яисә) хаталар ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүчегә яңадан рәсмиләштерелгән документны төзәтә һәм гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә) бирә (җибәрә);

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталар һәм (яисә) ялгышлар булмаган очракта, гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итүчегә мондый хаталарның һәм (яисә) ялгышларның булмавы турында язма рәвештә хәбәр итә.

3.9.2. Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) яңадан рәсмиләштерелгән документны җибәрү (бирү) тора.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Бүлекнең вазыйфаи затларының әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәвенә һәм башкаруына агымдагы контроль әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлешен һәм башкарылуын тикшерүләр уздыру юлы белән бүлек башлыгы, шулай ук министрның кураторлык итүче урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Агымдагы контрольне оештыру тәртибе һәм формалары министрның тикшерүдә тотучы урынбасары тарафыннан билгеләнә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүдә тоту Министрлык аппаратының әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

белешмәләрне һәм документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

гаризаларны һәм документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

Белешмә телефоннар һәм Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлары турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Министрлык, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм

гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр министрга бирелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи заты яисә Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http//mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең)

бердәм порталы аша (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлә. Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә карала һәм Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Хезмәт шартларына дәүләт
экспертизасы уздыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш
белән тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгы бланкында

________________________________
(мөрәҗәгать итүче)

________________________________
(мөрәҗәгать итүченең адресы)

**Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздырудан баш тарту турында хәбәр**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыруга _______________№____________ гариза буенча хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын башкаруның мөмкин түгеллеге турында хәбәр итә, мөрәҗәгать итүче:

______________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең (эш бирүченең, оешманың, предприятиенең, учреждениенең) тулы исеме күрсәтелә),
ИНН, ОГРН, телефон – юридик затлар өчен,
фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта) – физик затлар өчен)

максаты

______________________________________________________________________
(хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыруның максаты күрсәтелә: хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү, хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартларында эшләгән өчен гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеген бәяләү, хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартларын бәяләү)

эш бирүчедә

______________________________________________________________________.
(эш бирүченең (оешма, предприятие, учреждение), ИНН, ОГРН исеме)

чөнки

______________________________________________________________________.
(хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын үткәрүдән баш тарту сәбәпләренә нигезләү күрсәтергә)

Кәгазьдә тапшырылган документларның кире кайтарылуы турында хәбәр итәбез.

Хезмәт шартларына махсус бәя бирүнең сыйфатын бәяләү максатларында хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы түләү хисабына кертелгән акчаларны кире кайтаруны тәэмин итү өчен (түләү башкарылган очракта), акчаларны кире кайтаруга

беркетелгән гаризаны тутырып, акча күчерү өчен реквизитлар күрсәтүегезне сорыйбыз.

Баш тартуның күрсәтелгән сәбәпләре бетерелгән очракта, мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламенты нигезендә гаризаны һәм документларны кабат җибәрергә хокуклы.

Кушымта: акчаларны кире кайтару турында гариза 1 биттә 1 нөсхәдә.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
| (вазыйфасы) | (имзасы) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме) |

Татарстан Республикасы
хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрына
______________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

**Акчаларны кире кайтару турында гариза**

Мөрәҗәгать итүче
_____________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең (эш бирүченең, оешманың, предприятиенең, учреждениенең) тулы исеме, ИНН, ОГРН, телефон – юридик затлар өчен күрсәтелә; фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) – физик затлар өчен күрсәтелә)

Урнашу урыны
_____________________________________________________________.
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, электрон почта адресы (физик затларның электрон почта адресы (булган очракта)

Хезмәт шартларын махсус бәяләү сыйфатына экспертиза үткәргән өчен түләүне кире кайтаруны тәэмин итүегезне сорыйм, ______________ сум күләмендә, түләү йөкләмәсе № __________ «___» _____________, сәбәбе: _________________
_____________________________________________________________.
(хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын үткәрүдән баш тарту сәбәпләренә нигезләү күрсәтергә – баш тарту турында хәбәрдән)

Акча күчерү өчен реквизитлар (юридик затлар өчен):
Юридик зат исеме _____________________________________
ИНН______________________________
КПП______________________________
Исәп-хисап счеты_____________________
Банк______________________________
Корреспондент счеты_____________
БИК______________________________

Кушымта:
1. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырудан баш тарту турында хәбәр.
2. Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү өчен түләү турындагы документның таныкланган күчермәсе.

| ______________________ | __________________ | _______________ |
|---|---|---|
| (гариза бирүче юридик зат булган очракта, вазыйфа исеме | (имза) | (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)) |

М.У. (юридик затлар өчен (булган очракта)

«____»____________ ______ ел.

Хезмәт шартларына дәүләт
экспертизасы уздыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Рәвеше

(Оешмалар өчен мөрәҗәгать итүче оешма бланкында тутырыла)

Татарстан Республикасы
хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрына

___________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

**Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыруга гариза**

Мөрәҗәгать итүче

_______________________________________________________________
(эш бирүченең (оешма, предприятие, учреждение) тулы исеме, ИНН, ОГРН, телефоны – юридик затлар өчен; фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) – физик затлар өчен күрсәтелә)

Урнашу урыны

_______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, электрон почта адресы (физик затларда электрон почта адресы булган очракта)

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздырыла торган эш бирүче:

_______________________________________________________________
(эш бирүченең (оешма, предприятие, учреждение), ИНН, ОГРН исеме)

Дәүләт экспертизасы объекты буенча белешмәләр

_______________________________________________________________
(хезмәт шартларына карата хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрелергә тиешле структур бүлекчәсен күрсәтеп, эш урыннарының индивидуаль номерлары, аларда эшләүче хезмәткәрләрнең һөнәре (вазыйфалары) исеме)

Хезмәт шартларына элек үткәрелгән дәүләт экспертизалары турында белешмәләр (булган очракта):

_______________________________________________________________
(экспертиза бәяләмәсе датасы һәм номеры, үткәрү максаты, аларга карата экспертиза үткәрелә торган эш урыннары номерлары, хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) исеме, экспертиза бәяләмәсен биргән органның исеме (булган очракта тутырыла)

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрүегезне сорыйм, түбәндәге максатларда:

______________________________________________________________________________________,
(хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыруның максаты күрсәтелә: хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү, хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләгән өчен гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеген бәяләү), хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартларын бәяләү

һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә бирегез.
Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы өчен түләү турында белешмәләр
______________________________________________________________________________________
(экспертиза уздыру объекты хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру сыйфатын бәяләү булган очракта тутырыла; тутырылган очракта түләүне раслый торган түләү документының исеме, реквизитлары һәм датасы күрсәтелә; мөрәҗәгать итүченең счеты номеры, кредит оешмасының БИК, ИНН, кредит оешмасының исеме күрсәтелә; түләү гамәлдәге расланган хезмәт шартларын махсус бәяләү сыйфатына экспертиза уздырган өчен түләү күләмен билгеләү турында башкарма хакимият органының хезмәт буенча норматив хокукый акты белән)

Экспертизага тапшырылган документлар исемлеге:
______________________________________________________________________________________
(хезмәт шартларына дәүләт экспертизасына тапшырылган документлар исемлеге китерелә)

Мөрәҗәгать итүче

| | | |
|---|---|---|
| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
| (гариза бирүче юридик зат булган очракта, вазыйфа исеме | (имза) | (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) |

М.У. (юридик затлар өчен (булган очракта)
«____»________________ _______ ел.

Хезмәт шартларына дәүләт
экспертизасы уздыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Рәвеше

(Мөрәҗәгать итүче физик затлар өчен генә)

**Персональ белешмәләрне эшкәртүгә РИЗАЛЫК**

Мин,__________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме ,атасының исеме (булган очракта)

«Шәхси мәгълүматлар турында»[1] 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясындагы 4 пункты нигезендә, теркәлгән адрес:
______________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы документ: _____________________________________
______________________________________________________________.
(документның исеме, номеры, документны бирү датасы һәм аны биргән орган турындагы белешмәләр)

хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы үткәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәге адрес буенча: Казан ш., Волгоград ур., 47 йорт, минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм, атап әйткәндә:
______________________________________________________________,
(хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыруга гариза нигезендә шәхси белешмәләр субъектының ризалыгы бирелә торган шәхси белешмәләр исемлеге күрсәтелә)

ягъни «Шәхси мәгълүматлар турында»[2] 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга.

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып язма рәвештә кире алганчыга кадәр гамәлдә була.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләре белән танышуымны раслыйм, шәхси мәгълүматларны саклау өлкәсендәге хокуклар һәм бурычлар турында миңа аңлатылды.

| ____________________ | ______________ | ______________ |
|---|---|---|
| (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)) | (имза) | (дата) |

1. Россия Федерациясе законнарының 1 җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст.; 2011, № 31, 4701 ст.
2. Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст.; 2011, № 31, 4701 ст.

Хезмәт шартларына дәүләт
экспертизасы уздыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

**Хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру нәтиҗәләре турында хисапның бер өлеше булып торучы яисә теркәлә торган документлар исемлеге**

1. Хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыру комиссиясен төзү турында боерык (алга таба – эш бирүче комиссиясе).

2. Тиешле елда хезмәт шартларына махсус бәя (алга таба – хезмәт шартларына махсус бәя) бирелергә тиешле эш бирүче комиссиясе тарафыннан төзелгән эш урыннары исемлеге.

3. Эш урыннарында тикшеренүләр (сынаулар) һәм үлчәүләр уздырылырга тиешле потенциаль зарарлы һәм (яисә) хәвефле идентификацияләнгән җитештерү факторлары исемлеген теркәп, зарарлы һәм (яисә) куркыныч җитештерү факторларын идентификацияләү нәтиҗәләре турында эксперт бәяләмәсе.

4. Эксперт тарафыннан әлеге «хезмәт шартларын махсус бәяләү турында»2013 елның 28 декабрендәге 426-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән Эш урыннарында тикшерелергә (сыналырга) һәм үлчәлергә тиешле зарарлы һәм (яисә) куркыныч җитештерү факторлары исемлеге (булган очракта).

5. Тикшерелергә (сыналырга) һәм үлчәүләргә тиешле зарарлы һәм (яисә) хәвефле җитештерү факторларын идентификацияләү яисә билгеләү нәтиҗәләрен комиссия раслый торган документлар (эш бирүче комиссиясе утырышлары беркетмәләре).

6. Эксперт тарафыннан хезмәт шартларына махсус бәя бирү барышында кабул ителгән башка бәяләмәләр һәм карарлар (булган очракта).

7. Җитештерү мохитенең һәм эш урыннарында хезмәт барышының зарарлы һәм (яисә) куркыныч факторларын тикшерү (сынау) һәм үлчәү нәтиҗәләрен үз эченә алган документлар, хезмәт шартларын җитештерү (лаборатор) контроле беркетмәләре (хезмәт шартларына махсус бәя үткәргән оешма эксперты тәкъдиме буенча эш бирүче комиссиясе аларны куллану турында карар кабул иткән очракта).

8. Гаризада күрсәтелгән эш урыннарында эш вакыты (эш сменасы) хронометражы картасы (әгәр идентификацияләнгән зарарлы җитештерү факторы йогынты вакытын исәпкә алуны таләп итсә).

9. Эш бирүче комиссиясе беркетмәләре (карарлары) (булган очракта).

10. Комиссия әгъзаларының аерым фикерләре (булган очракта).

Хезмәт шартларына дәүләт
экспертизасы уздыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

**Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасына тапшырыла торган, кирәк булганда Министрлык тарафыннан өстәмә рәвештә соратып алына торган өстәмә документларның үрнәк исемлеге**

1. Эш бирүченең хезмәт шартларына махсус бәя үткәрүгә оешма белән килешүе (контракты).

2. Хезмәт шартларына махсус бәя үткәрү графигы.

3. Кулланыла торган җайланмалар, чимал һәм материаллар исемлеге, шулай ук хезмәт шартларына махсус бәя үткәрелгән эш урыннарында башкарыла торган эшләр характеристикасы.

4. Гаризада күрсәтелгән эш урыннарында хезмәт шартларына махсус бәя уздыру вакытына гамәлдә булган эш яки вазыйфаи инструкцияләр.

5. Гаризада күрсәтелгән эш урыннарында хезмәтне саклау буенча хезмәт шартларына махсус бәя уздыру вакытына гамәлдә булган инструкцияләр.

6. Җиһазларга паспортлар, җиһазларны эксплуатацияләү буенча белешмәләр.

7. Медицина оешмаларында хезмәт шартларына махсус бәя үткәргәндә өстәмә рәвештә ВИЧ-инфекция, туберкулез белән авыручылар, актив туберкулез авырулары турында, медицина оешмасы хезмәт күрсәтә торган районда яшәүче пациентларда теркәлгән авырулар саны турында, медицина оешмасының стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләре эшчәнлеге турында федераль статистик күзәтчелек формалары күрсәткечләре соратып алына (булган очракта).

Хезмәт шартларына дәүләт
экспертизасы уздыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
6 нчы кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы бланкында

______________________________________
(эш бирүченең, оешмаларның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең тулы исеме)

______________________________________
(эш бирүченең (оешма, предприятие, учреждение) адресы)

**Эш урыннары хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы объекты булган эш бирүчедән документация сорату**

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 213 статьясы һәм «Хезмәт шартларын махсус бәяләү турында» 2013 елның 28 декабрендәге 426-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясы нигезендә, түбәндәгеләр нигезендә:

____________________________________________________________________________.
(документның номеры, датасы, исеме, мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын (алга таба – дәүләт экспертизасы) гамәлгә ашыра, ул түбәндәге максатларда уздырыла:

____________________________________________________________________________.
(хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын уздыруның максаты күрсәтелә: хезмәт шартларын махсус бәяләүне уздыруның сыйфатын бәяләү, хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләгән өчен гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеген бәяләү, хезмәткәрләрнең фактагы хезмәт шартларын бәяләү)

эш бирүчедә

____________________________________________________________________________
(эш бирүченең (оешма, предприятие, учреждение), ИНН, ОГРН исеме)

түбәндәге эш урыннарында:

____________________________________________________________________________.
(эш урыннары номерлары, аларда эшләүче хезмәткәрләрнең һөнәрләре (вазыйфалары) исеме, урнашуының фактагы адресы)

Югарыда бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә, әмма әлеге гарызнамәне алган вакыттан алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, сорала торган документлар исемлеге нигезендә дәүләт экспертизасын уздыру өчен кирәкле документларның таныкланган күчермәләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы адресына җибәрүегезне (кушымта итеп бирелә) яисә, күрсәтелгән документларны тапшыру

мөмкин булмаган очракта, сәбәпләрен күрсәтеп, бу хакта язмача хәбәр итүегезне сорыйм.

Кушымта: соралучы документлар исемлеге ___ биттә, 1 нөсхәдә.

______________________________ ________________________ ______________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Хатка кушымта
«____» __________ел, № ________

Сорала торган документлар (материаллар) исемлеге

1)…
2)
…

________________________________________________________________________________
(соратыла торган документларның (материалларның) исемнәре күрсәтелә)

Хезмәт шартларына дәүләт
экспертизасы уздыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
7 нче кушымта

Рәвеше

(Оешмалар өчен мөрәҗәгать итүче оешма бланкында тутырыла)

Татарстан Республикасы
хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрына
______________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

**Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе дубликатын бирүгә гариза**

Мөрәҗәгать итүче
_________________________________________________________________,
(эш бирүченең (оешма, предприятие, учреждение), ИНН, ОГРН, тулы исемен, телефонын – юридик затлар өчен; фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта) – хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру максатларында мөрәҗәгать иткән һәм бәяләмәнең төп нөсхәсен алган физик затлар өчен күрсәтергә)

урнашу
урыны_________________________________________________________________
_____.
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, электрон почта адресы (физик затларның электрон почта адресы (булган очракта)

Оригиналның югалуына бәйле рәвештә, хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсенең дубликатын бирүегезне сорыйм, максатлары:
_________________________________________________________________.
(хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру максатларының берсен сайларга һәм күрсәтергә: хезмәт шартларына махсус бәя бирү сыйфатын бәяләү, хезмәткәрләргә зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләгән өчен гарантияләр һәм компенсацияләр бирүнең дөреслеген бәяләү, хезмәткәрләрнең факттагы хезмәт шартларын бәяләү)

«___» __________ _____ ел, №_______, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан эш бирүчегә карата уздырылган
_________________________________________________________________.
(эш бирүченең (оешма, предприятие, учреждение), ИНН, ОГРН исеме)

Мөрәҗәгать итүче

| | | |
|---|---|---|
| ________________________ (юридик затлар өчен вазыйфа исеме) | __________________ (имза) | ____________________ (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)) |

Хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы уздыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Рәвеше

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгы

кемнән________________________________
(мөрәҗәгать итүченең тулы исеме - юридик затлар өчен,
мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. - физик затлар өчен)

______________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, электрон почта адресы (булган очракта), телефоны)

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Техник хатаны төзәтүегезне сорыйм _____________________________________
__________________________________________________________________________,
хезмәт шартларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсендә «____»__________ №__________ (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрдә) җибәрелгән.

Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча хәбәрләмәне түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:
__________________________________________________________________________.
(почта адресы буенча язма рәвештә), электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә)

Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) түбәндәгечә бирүне сорыйм:

__________________________________________________________________________
(шәхсән, почта аша)

«__» ______________ 20__ ел. ______________________ __________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)